РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь 2025 ел г. Альметьевск №3052

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы торак йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2025 елның 29 августындагы 2161 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып китүче өзеклекләр белән үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы торак йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2025 елның 29 августындагы 2161 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

заказ № 4553-940

1.1. Карар исемендә, карарның 1 пунктында һәм карарның 1 нче кушымтасында «күпфатирлы торак йорт» сүзләрен «күпфатирлы йорт» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Карарның 1 нче кушымтасында:

6 пунктта «торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү автомат рәвештә ябыла торган җайланмаларсыз, шул исәптән» сүзләрен «автомат рәвештә ябыла торган җайланмаларсыз торак биналарны агымдагы ремонтлау, шул исәптән» сүзләренә алмаштырырга»;

7 пунктта «торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм автомат рәвештә ябыла торган җайланмалары булган йорт яны территориясен төзекләндерү (күпфатирлы йортта гомуми милек составында булганда)» сүзләрен «автомат рәвештә ябыла торган җайланмалары булган торак биналарны агымдагы ремонтлау (күпфатирлы йортта гомуми милек составында булганда)» сүзләренә алмаштырырга»;

16 пунктта «җылылык энергиясен исәпкә алу приборларыннан һәм һава торышын җайга салу узелларыннан башка үзәк җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту» сүзләрен «җылылык энергиясен исәпкә алу приборларыннан һәм һава торышын җайга салу узелларыннан башка җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта «җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары һәм һава торышын җайга салу узеллары булган җылылык алмаштыру җайланмалары белән җиһазландырылган үзәкләштерелгән җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту» сүзләрен «җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары һәм һава торышын җайга салу узеллары белән җиһазландырылган җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктта «җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары һәм һава торышын җайга салу узеллары булган үзәк җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту» сүзләрен «җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары һәм һава торышын җайга салу узеллары булган җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту» сүзләренә алмаштырырга.;

19 пунктта «җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары булган үзәкләштерелгән җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту, һава торышын җайга салу узелларыннан башка» сүзләрен «җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары булган җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту, һава торышын җайга салу узелларыннан башка» сүзләренә алмаштырырга»;

25 пунктта «газ челтәрләренә техник диагностика» сүзләрен «йорт эчендәге газ җиһазына техник диагностика ясау (түләү диагностика ясау срогы башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. А. Габдуллинга йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов